| Республика Татарстан<br>Совет Иляксазского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районы Илексаз авыл<br>җирлеге советы |
| --- | --- |

РЕШЕНИЕ — КАРАР

2019 ел 14 ноябрь — № 25

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге составына керүче Игәнә-Баш авылында 2020 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Илексаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән, 1 нче төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2020 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга:

- Игәнә-Баш авылында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;;
- Игәнә-Баш авылында «Беларус 82.1» тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтләре өчен түләү);
- Игәнә-Баш авылында урамнарны яктырту лампочкалары сатып алу.

Илексаз авыл җирлеге Советы рәисе: Ф.М.Гыйлфанов